**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯНА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ШАХМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**Яңа Чишмә муниципаль районы, 423183,**
**Шахмай авылы, Үзәк ур., 40**
**e-mail:Shah.Nsm@.tatar.ru**
**тел.(8-84348) 38-4-96; факс: (8-84348) 38-4-46**

**СОВЕТ**
**ШАХМАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**Новошешминского муниципального района**
**423183, село Шахмайкино, ул.Центральная,40**
**e-mail:Shah.Nsm@.tatar.ru**
**тел.(8-84348) 38-4-96; факс: (8-84348) 38-4-46**

---

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авыл җирлеге Советы
КАРАРы

2016 елның 24 октябре №19-41

«Шахмай авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү, яшелләндерү, чисталык һәм тәртипне саклау кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»

Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры Ф.С. Габделганиев мөрәҗәгате нигезендә 2016 елның 12 августындагы 7054/13 номерлы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Шахмай авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү, яшелләндерү, чисталык һәм тәртип кагыйдәләренә түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

- Ял итү урыннарында, кешеләр күпләп җыела торган урыннарда, пляжларда, скверларда автотранспорт чаралары хәрәкәтен һәм туктап торуларын тыю.

2. Әлеге карарны Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Шахмай авылы,Үзәк урамы,47 йорт (“Заман” кибете янында), Чаллы Башы авылы, Үзәк урамы( 55 нче йорт янында), Чертуш авылы, Сөембикә урамы, 16 йорт (“Алсу” кибете янында) адресы буенча урнашкан авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында игълан итәргә (бастырып чыгарырга).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Советының Законлылык, экология, җирдән файдалану, торак - коммуналь хуҗалык һәм территорияне төзекләндерү мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Шахмай
авыл җирлеге башлыгы урынбасары К.Н.Хайруллин